| | | |
|---|---|---|
| **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ УРАЗАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**<br>423750, Уразай авылы, Центральная ур., 4 йорт | | **СОВЕТ УРАЗАЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**<br>423750, дер.Ильчебаево, ул. Центральная, дом 4 |
| **РЕШЕНИЕ**<br>**«22» ноябрь 2024 ел** | | **КАРАР**<br>**№ 10** |

**Үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Актаныш муниципаль районы Уразай авыл җирлегенең Илчебай авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 - ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2024 елның 22 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде. Актаныш муниципаль районы Уразай авыл җирлегенең Илчебай авылы : «Уразай авыл җирлегенең Илчебай торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннарыннан, көндезге бүлектә белем алучы студентлардан, 1 төркем инвалидлардан, балачактан инвалидлардан, Россия Федерациясендә һәм аларның гаилә әгъзаларын өлешчә мобилизацияләү кысаларында мобилизацияләнгән гражданна, Украинада махсус хәрби операция зонасында контракт буенча хәрби хезмәт узучы хәрби хезмәткәрләрләрдән тыш, 2025 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә ризамы?
алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп:
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту(урам юлларын карап тоту һәм ремонтлау);
-су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау(су белән тәэмин итү челтәрләрен тоту, ремонтлау)
-ремонт, коймалар кору, традицион Күмү урыннарын төзекләндерү (инвентарь сатып алу );
- урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформаторларны һәм алар астындагы башка подстанцияләрне һәм мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү, электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау(урам яктыртуын карап тоту һәм ремонтлау);
- һәйкәлләрне (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкәрләре) булмаган) төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияләрне төзекләндерү( һәйкәлне ремонтлау һәм карап тоту).

«Эйе» -33 «Каршы»- 0 «Тыелып калды » - 0

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә 61 граждан, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 33 граждан кертелде.
Ачык тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде::
«Эйе» позициясе өчен 33 граждан тавыш бирде;
«Каршы» позициясе өчен 0 граждан тавыш бирде.
«тыелып калдылар» позиция өчен» - 0 граждан тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены хәл итте:
1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Уразай авыл җирлегенең Илчебай торак пунктында гражданнар җыенын узган дип таныргa, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.
2. «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Уразай авыл җирлегенең Илчебай торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннарыннан, көндезге бүлектә укучы студентлардан, 1 төркем инвалидлардан, балачактан инвалидлардан, Россия Федерациясендә һәм аларның гаилә әгъзаларын өлешчә мобилизацияләү кысаларында мобилизацияләнгән гражданнар, Украинада махсус хәрби операция зонасында контракт буенча хәрби хезмәт узучы хәрби хезмәткәрләрлэрдән тыш, 2025 елда үзара салым кертүгә 500 сум күләмендә,Мәсьәлә буенча карарны танырга,җыелган акчаны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә :
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту(урам юлларын карап тоту һәм ремонтлау);
-су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау(су белән тәэмин итү челтәрләрен тоту, ремонтлау)
-ремонт, коймалар кору, традицион Күмү урыннарын төзекләндерү (инвентарь сатып алу );
- урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформаторларны һәм алар астындагы башка подстанцияләрне һәм мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү, электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау(урам яктыртуын карап тоту һәм ремонтлау);
- һәйкәлләрне (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкәрләре) булмаган) төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияләрне төзекләндерү( һәйкәлне ремонтлау һәм карап тоту).

3.Әлеге карарны Уразай авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга. http://aktanysh.tatar.ru.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Уразай авыл җирлеге башлыгы Шәймәрданова Г. С.

Совет
УРАЗАЕВСКОГО
сельского поселения
ИНН 1604001390